**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 20 мартындагы 1128р номерлы боерыгы**

**Казан шәһәре территориясендә коммуникация күрсәткече рәвешендәге реклама корылмасы урнаштыруга һәм аңардан файдалануга килешү төзү хокукына сатулар оештыру турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 26 июнендәге 2544 номерлы «Казан шәһәре территориясендә реклама корылмалары урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр төзү хокукына сатулар үткәрү тәртибе турында»гы карары нигезендә, Казан шәһәре территориясендә коммуникация күрсәткече рәвешендәге реклама корылмасы урнаштыруга һәм аңардан файдалануга килешү төзү хокукына сатулар үткәрү максатыннан **йөкләмә бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсенә (Ә.Р.Баһаутдинов) Казан шәһәре территориясендә коммуникация күрсәткече рәвешендәге реклама корылмасы урнаштыруга һәм аңардан файдалануга килешү төзү хокукына сатулар оештырырга һәм үткәрергә.

2. Казан шәһәре территориясендә реклама корылмасы урнаштыруга һәм аңардан файдалануга килешү буенча түләүнең башлангыч (минималь) күләмен исәпләү тәртибе белән каралган Казан шәһәре территориясендә коммуникация күрсәткече рәвешендәге реклама корылмасы урнаштыруга һәм аңардан файдалануга килешү буенча түләүнең башлангыч (минималь) күләмен исәпләү өчен Р параметры күрсәткечен 2238 сумга тигез дип рәсларга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**